**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№7016**
**11.12.2015 ел**

2016 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең сәнгать-эстетика юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының сәнгать-эстетика юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2009 елның 14 декабрендәге 854 нче карары, шәһәр Уставы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 2 декабрендәге 01/1941 санлы хаты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. 2016 елга расларга:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең сәнгать-эстетика юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны, 1 нче кушымтада каралганча;

2) сәнгать-эстетика юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга төзәтмә кертү коэффициентын 0,5 күләмендә.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә сәнгать-эстетика юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны әлеге карарның 1 пунктында каралган норматив чыгымнарга туры китереп тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы Ә.А. Галиәкбәровага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы, мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе башлыгы Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                    Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2015 елның 11 декабрендәге
7016 нчы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең
сәнгать-эстетика юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү
мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив
чыгымнар

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар (елына 1 укучыга, сумнарда) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өчьеллык укыту вакыты | дүртьеллык укыту вакыты | бишьеллык укыту вакыты | җидееллык укыту вакыты | башлангыч һөнәри юнәлеш |
| Музыка сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 36 445 | 40 176 | 58 473 |
| Рәсем сәнгате | шәһәр җирлеге | | 21 530 | | 17 753 | 45 566 |
| Хореография сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 41 080 | 33 340 | 131 757 |
| Гомуми эстетика сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 17 312 | | |
| Фольклор сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 37 283 | 34 713 | 61 871 |
| Эстрада-джаз сәнгате | шәһәр җирлеге | 60 705 | | 53 996 | | 95 596 |
| Театр сәнгате | шәһәр җирлеге | 31 677 | | 27 623 | 26 752 | 45 124 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова